ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 22 марты №355

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында мәдәният һәм белем бирү өлкәсендә хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча Иҗтимагый совет турында Нигезләмәне раслау турында

2017 елның 5 декабрендәге «Мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә оешмалар һәм медик-социаль экспертиза федераль учреждениеләре тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыруны камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 392-03 номерлы Федераль закон нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Советының 2016 елның 14 июлендәге 72 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге каршындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәнең 2.4 пунктына таянып, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында мәдәният һәм белем бирү өлкәсендә хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча Иҗтимагый совет турында Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны рәсми публикатор – “Лениногорские вести” газетында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны “Лениногорск муниөипаль районы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары В.В. Друкка йөкләргә.

Җитәкче Н.Р. Залаков

В.В.Друк